КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 11 сентябрь г.Казань № б-1797

Татарстан Республикасында торак-коммуналь комплексның кадрлар потенциалын тәэмин итү өчен кадрлар әзерләү системасының алга таба эшләвен тәэмин итү максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү чаралары планын (алга таба – План) расларга.

2. Планның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 11 сентябрь, б-1797 нче
боерыгы белән расланды

2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү чаралары планы

| Т/с | Чара исеме | Үтәү срогы | Документның төре | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 31 март, 208 нче карары белән расланган Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламенты нигезендә торак-коммуналь хуҗалык оешмалары өчен кадрлар әзерләүгә ихтыяҗ фаразын формалаштыру | 2022 – 2026 еллар | Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (килешү буенча) |
| 2. | 2022 – 2026 елларга торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе өчен кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм белгечләрнең ква- | 2022 елның I кварталы | 2022 – 2026 елларга торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе өчен кадрлар әзерләү, яңадан | Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (килешү буенча), «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлары белән идарә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | лификациясен күтәрү буенча муниципаль планнар кабул итү | | әзерләү һәм белгечләрнең квалификациясен күтәрү буенча муниципаль планнар | итүчеләр оешмалары бердәмлеге» ассоциациясенең үз-үзен җайга салучы оешмасы (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Коммуналь предприятиеләр берлеге» эш бирүчеләр төбәк тармак берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 3. | Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кадрларны яңадан әзерләүгә һәм аларның квалификациясен күтәрүгә заявкалар формалаштыру | 2022 – 2026 еллар | торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кадрларны яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү буенча ел саен эшләнә торган республика планы | «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлары белән идарә итүчеләр оешмалары бердәмлеге» ассоциациясенең үз-үзен җайга салучы оешмасы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (килешү буенча) |
| 4. | Торак-коммуналь хуҗалык оешмалары кадрларын һөнәри яңадан әзерләүне һәм аларның квалификациясен | 2022 – 2026 еллар | муниципаль берәмлекләрнең квартал саен бирелә торган | Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (килешү буенча) «Татарстан Республикасының |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | күтәрүне үткәрү | | хисаплары | күпфатирлы йортлары белән идарә итүчеләр оешмалары бердәмлеге» ассоциациясенең үз-үзен җайга салучы оешмасы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 5. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында торак-коммуналь хуҗалык оешмаларының заявкалары буенча торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе өчен һөнәрләр буенча эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү | 2022 – 2026 еллар | аналитик материаллар | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| 6. | «Белемле кулланучы мәктәбе» партия проекты һәм «Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләреннән файдалану-чылар өчен әлифба» методик пособиесе материаллары буенча дәрестән тыш эшчәнлек һәм факультатив дәресләр вакытында гомуми белем бирү системасында | 2022 – 2026 еллар | аналитик материал | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә төбәк иҗтимагый контроль үзәге» ассоциациясе (киле-шү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | дәресләр оештыру | | | «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлары белән идарә итүчеләр оешмалары бердәмлеге» ассоциациясенең үз-үзен җайга салучы оешмасы (килешү буенча) |
| 7. | Торак-коммуналь хуҗалык оешмаларында алга таба эш урнашу максаты белән яңа профильле юнәлешләр буенча белем, шул исәптән өстәмә һөнәри белем алу өчен гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар һәм эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләрендә теркәлгән затлар арасында һөнәри юнәлеш бирү системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү | ел саен | аналитик материал | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (килешү буенча) |
| 8. | Торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләрендә һәм оешмаларында һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның эшкә урнашуына анализ ясау | 2022 – 2026 еллар | квартал саен бирелә торган хисаплар | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының мәгариф оешмалары |
| 9. | «Белемле кулланучы мәктәбе» партия проекты кысаларында күпфатирлы йорттагы урыннарның актив милекчеләренә торак белеме бирүне оештыру | 2022 – 2026 еллар | квартал саен бирелә торган хисаплар | «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә төбәк иҗтимагый контроле үзәге» ассоциациясе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (килешү буенча) |